**Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районы**
**Иске Илдерәк авыл җирлеге Советы**
**КАРАР**

№ 11 20.11.2015 ел

**Иске Илдерәк авыл җирлеге**
**2016 елга бюджеты турында**

**Пункт 1**

1. Иске Илдерәк авыл җирлеге бюджетының 2016 елга төп характеристикалары раслансын:

1) Иске Илдерәк авыл җирлеге бюджетының гомуми керемнәре 3094 мең сум тәшкил итә;

2) Иске Илдерәк авыл җирлеге бюджетының гомуми чыгымнары күләме 3094 мең сум.

3) Иске Илдерәк авыл җирлеге бюджеты дефицитының чик күләме 0 мең сум.

2.Иске Илдерәк авыл җирлеге бюджеты дефицитын финанслау чыганакларын билгеләргә:

2016 елга әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә;

**Пункт** 2

2017 елның 1 гыйнварына .Иске Илдерәк авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча Эчке муниципаль бурычның югары чиге 0 мең сум, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә билгеләнергә тиеш.

**Пункт 3**

Иске Илдерәк авыл җирлеге бюджетында әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә 2016 елга фаразлана торган керем күләмен исәпкә алырга. **Пункт 4**

"Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 60.1 статьясындагы 2 пункты һәм муниципаль район Уставының 79 статьясындагы 9 пункты нигезендә әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә 2016 елга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәрне бүлү нормативларын расларга"»

**Пункт 5**

1. Иске Илдерәк авыл җирлеге – Аксубай муниципаль районы, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Иске Илдерәк авыл җирлеге-Аксубай муниципаль районы, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары бюджеты дефицитын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

**Пункт 6**

1. Бюджет ассигнованиеләрен 2016 елга бюджет чыгымнарын классификацияләүнең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгым төрләре буенча әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә бүлүне расларга;

2. Иске Илдерәк авыл җирлегенең 2016 елга чыгымнарның ведомство структурасын әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялар (Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлегенең муниципаль программалары һәм программадан тыш эшчәнлек юнәлешләре), чыгым төрләре төркемнәре,

бүлекләр, 2016 елга бюджет чыгымнарын классификацияләү бүлекчәләре буенча әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә бүлүне расларга.

4. 2016 елга ачык норматив йөкләмәләрне үтәүгә бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 0 мең сум күләмендә расларга.

**Пункт 7**

Иске Илдерәк авыл җирлеге бюджетында Аксубай муниципаль районы бюджетыннан 2016 елга бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә 1521,4 мең сум күләмендә дотацияләр күләмен исәпкә алырга.

**Пункт 8**

Иске Илдерәк авыл җирлеге бюджетында Аксубай муниципаль районы бюджетыннан 2016 елга җирлек бюджетларының балансылыгын тәэмин итү чараларына ярдәм итүгә 16,0 мең сум күләмендә дотация күләмен исәпкә алырга.

**Пункт 9**

Иске Илдерәк авыл җирлеге бюджетында 2016 елга Граждан хәле актларын дәүләт теркәве буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга Аксубай муниципаль районы бюджетыннан субвенцияләр күләмен 1000 сум итеп исәпкә алырга.

**Пункт 10**

Иске Илдерәк авыл җирлеге бюджетында 2016 елга хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Аксубай муниципаль районы бюджетыннан субвенцияләр күләмен 111 мең сум күләмендә исәпкә алырга.

**Пункт 11**

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» 2011 елның 7 декабрендәге 6-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге бюджетында исәпкә алырга:

Иске Илдерәк авыл җирлеге бюджетыннан район бюджетына 12 мең сум күләмендә төзелгән килешүләр нигезендә тышкы муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыруга бирелә торган бюджетара трансфертлар

**Пункт 12**

1. Иске Илдерәк авыл җирлеге бюджеты башкарма комитеты 2016 елда бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм башка оешмаларының муниципаль хезмәткәрләре һәм хезмәткәрләре санын, шулай ук аларны тотуга чыгымнарны арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

**Пункт 13**

Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге бюджеты акчаларының калдыклары 2015 елда әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар китерү, эшләр башкару, хезмәт күрсәтү өчен Иске Илдерәк авыл җирлеге исеменнән төзелгән муниципаль контрактларга түләүгә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә, 2016 елда Аксубай муниципаль районы Иске Илдерәк авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлтелә.

**Пункт 14**

2016 елда Иске Илдерәк авыл җирлеге милкендәге һәм мәдәният һәм сәнгать бюджет учреждениеләренә оператив идарәгә тапшырылган мөлкәтне арендага бирүдән кергән керемнәр Иске Илдерәк авыл җирлеге бюджеты керемнәре составына кертелә һәм әлеге карар нигезендә бюджет йөкләмәләрен үтәүгә кулланыла.

**Пункт 15**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләргә ярашлы рәвештә Иске Илдерәк авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

**Пункт 16**

Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Аксубай муниципаль районы
Иске Илдерәк авыл җирлеге
Совет Рәисе: В.К. Альметкин